СОВЕТ МОРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **Морт авылы** **КАРАР**

№ 74 «16» декабрь 2022 ел

**Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының 24.12.2009 № 19 «Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләр булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Урман кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә, Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә үсә торган яшел үсентеләрдән файдалану һәм саклау процессын тәртипкә китерү максатларында, Алабуга шәһәр прокуроры таләпләрен карап, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ:

1. Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының 24.12.2009 ел, № 19 Морт авыл җирлеге Советы тарафыннан расланган яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Яшел үсентеләрне кисүне күздә тоткан рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты эшнең катлаулылыгына һәм күләменә карап ике елга кадәр билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәисе Ф. Ф. Закиров